**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 23 маендагы 1615 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2015 елның 31 декабрендәге 4666 номерлы карары белән расланган**
**«Әмәт» территориясен планлаштыру проектына**
**үзгәрешләр кертү турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45 һәм 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 июлендәге 722 номерлы «2022, 2023, 2024 һәм 2025 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне ызанлау проектларын раслау һәм, җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрмичә, әлеге проектларга үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында»гы карарына таянып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 31 декабрендәге 4666 номерлы карары белән расланган «Әмәт» территориясен планлаштыру проектына, территорияне планлаштыру проектының аерым өлешләрен әлеге карарга кушымта нигезендә раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны, борылыш нокталары координаталары белән кызыл линияләр күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымы фрагментыннан (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 23 маендагы
1615 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2015 елның 31 декабрендәге 4666 номерлы карары белән расланган**
**«Әмәт» территориясен планлаштыру проектына**
**кертелә торган үзгәрешләр**

1. Җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, территорияне план буенча үстерү характеристикалары, шул исәптән территориядәге төзелешнең тыгызлыгы һәм параметрлары, территорияне үстерү өчен кирәкле социаль, транспорт хезмәте күрсәтү һәм инженерлык-техник яктан тәэмин итү системаларын үстерү характеристикалары турындагы нигезләмәдә:

1.1. 1.2 пунктта «23,85» санын «26,25» санына алмаштырырга, «16,23» санын «16,54» санына алмаштырырга;

1.2. 1.7 пунктта:

1.2.1. «196,60» санын «225,6» санына алмаштырырга;

1.2.2. түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«Нестеров Чокыры урамы тирәсендә фатирларның гомуми мәйданы 29000 кв. м, катларның максималь саны 25 кә кадәр булган һәм 690 кв. м мәйданда эченә кертеп-кушып төзелгән торак булмаган билгеләнештәге биналар белән күпфатирлы торак төзү каралган. Гомуми белем бирү мәктәпләрендәге урыннарга булган ихтыяҗ 166 урын тәшкил итә, балалар бакчаларында – 80 урын.

Төзелә торган торакларны балалар бакчалары белән тәэмин итү – планлаштырыла торган, 80 урынга исәпләнгән балалар бакчасы хисабына; гомуми белем бирү мәктәпләре белән тәэмин итү «98 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе хисабына гамәлгә ашырылачак.

Планлаштырыла торган күпкатлы торак төзелеше өчен төзелешне җайга салу линияләре (кызыл линияләрдән ераклыклар) кызыл линияләр, күпкатлы торак төзелешен план буенча урнаштыру зонасы чикләре белән тәңгәл килә, җир кишәрлекләренең алгы, кырый, арткы чикләреннән минималь ераклык 0 гә тигез итеп билгеләнә»;

1.3. 2 пунктта «12» санын «13» санына алмаштырырга, «1710» санын «1790» санына алмаштырырга;

1.4. 3 пунктта:

1.4.1. «3107» санын «3459» санына алмаштырырга;

1.4.2. түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«Җәяүлеләр-транспорт элемтәсен Нестеров Чокыры, Заслонов, Нестеров Авышлыгы урамнары буйлап урнаштыру планлаштырыла.

Нестеров Чокыры урамы тирәсендә планлаштырыла торган торак төзелеше өчен парковка урыннарына булган ихтыяҗ 352 машина урыны тәшкил итә.

Урнаштыру ысулы һәм урыны (ачык парковкалар, һәм/яки җир өсте паркинглары, һәм/яки җир асты паркинглары, һәм/яки стилобатлар) проектлаштыруның алдагы стадияләрендә билгеләнә, 50 машина урыны «Нестеров» торак комплексы чикләрендә каралган.

Торак фондының, йорт эченә кертеп-кушып төзелгән биналарның мәйданы кимегән очракта, ихтыяҗлар күрсәткечләре, факттагы күрсәткечләрдән чыгып, гамәлдәге нормативлар нигезендә киметелергә мөмкин»;

1.4.3. түбәндәге эчтәлекле таблица белән тулыландырырга:

«Урам-юл челтәрен урнаштыру максатыннан
мәҗбүри алынырга/резервланырга тиешле җир кишәрлекләре,
шулай ук транспортта узып йөрү өчен сервитут билгеләү
планлаштырыла торган җир кишәрлекләре турында белешмәләр

| № | Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Максат | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1 | 16:50:011204:11 | Урам-юл челтәре | Мәҗбүри алу |
| 2 | 16:50:011202:39 | Урам-юл челтәре | Мәҗбүри алу (өлешчә) |
| 3 | 16:50:011202:34 | Урам-юл челтәре | Мәҗбүри алу |
| 4 | 16:50:011207:123 | Урам-юл челтәре | Резервлау |
| 5 | 16:50:011207:37 | Урам-юл челтәре | Планлаштырыла торган сервитут |
| 6 | 16:50:011207:122 | Урам-юл челтәре | Планлаштырыла торган сервитут |
| 7 | 16:50:000000:5631 | Урам-юл челтәре | Резервлау (өлешчә) |
| 8 | 16:50:011207:36 | Урам-юл челтәре | Планлаштырыла торган сервитут |
| 9 | 16:50:011207:110 (җирдән бердәм | Урам-юл челтәре | Резервлау (өлешчә) |

| № | Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Максат | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| | файдалану 16:50:000000:40) | | |
| 10 | 16:50:011204:19 | Урам-юл челтәре | Резервлау (өлешчә) |
| 11 | 16:50:011207:20 | Урам-юл челтәре | Планлаштырыла торган сервитут |
| 12 | 16:50:000000:26231 | Урам-юл челтәре | Мәҗбүри алу (өлешчә) |
| 13 | 16:50:000000:35103 | Урам-юл челтәре | Мәҗбүри алу (өлешчә) |
| 14 | 16:50:011208:277 | Урам-юл челтәре | Мәҗбүри алу |
| 15 | 16:50:000000:34319 | Урам-юл челтәре | Мәҗбүри алу (өлешчә) |
| 16 | 16:50:000000:35989 | Урам-юл челтәре | Мәҗбүри алу (өлешчә) |
| 17 | 16:50:011208:278 | Урам-юл челтәре | Мәҗбүри алу |
| 18 | 16:50:011204:10 | Урам-юл челтәре | Мәҗбүри алу |
| 19 | 16:50:000000:17333 | Урам-юл челтәре | Планлаштырыла торган сервитут |
| 20 | 16:50:011202:158 | Урам-юл челтәре | Мәҗбүри алу (өлешчә) |
| 21 | 16:50:011207:125 | Урам-юл челтәре | Планлаштырыла торган сервитут |
| 22 | 16:50:011206:34 (җирдән бердәм файдалану 16:50:000000:40) | Урам-юл челтәре | Резервлау (өлешчә) |
| 23 | 16:50:011208:280 | Урам-юл челтәре | Мәҗбүри алу |
| 24 | 16:50:011204:18 | Урам-юл челтәре | Мәҗбүри алу (өлешчә) |
| 25 | 16:50:011206:26 | Урам-юл челтәре | Резервлау (өлешчә) |
| 26 | 16:50:011206:2 | Урам-юл челтәре | Мәҗбүри алу |
| 27 | 16:50:011206:3 | Урам-юл челтәре | Мәҗбүри алу |
| 28 | 16:50:011206:287 | Урам-юл челтәре | Мәҗбүри алу (өлешчә)» |

1.5. 4 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«Заслонов, Нестеров Чокыры урамнарында урнаштыру планлаштырыла торган объектлар территорияләрендә планлаштыру проекты белән гамәлдәге челтәрләрне күчереп салу һәм демонтажлау каралган.

Балалар бакчасы һәм планлаштырыла торган торак төзелеше өчен хуҗалык ихтыяҗларында һәм эчә торган судан файдалану чыгымы тәүлегенә

289,27 куб. м тәшкил итә. Проект буенча планлаштырыла торган торак төзелешен салкын су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасына Нестеров Чокыры урамында урнашкан гамәлдәге d315 мм суүткәргечтән тоташтыру каралган. Планлаштырыла торган балалар бакчасын Вишневский урамы, 61а адресы буенча урнашкан торак йорт тирәсендә гамәлдәге Ø315 мм суүткәргечкә аны үзгәртеп төзү планлаштырыла торган урында тоташтыру каралган.

Планлаштырыла торган объектлардан суны читкә чыгару (исәпләнгән чыгымы – тәүлегенә 289,27 куб.м) өчен аларны гамәлдәге канализация коллекторына тоташтыру каралган (торак төзелеше өчен – Заслонов урамы, 40 адресы буенча урнашкан торак йорт тирәсендә һәм Нестеров Чокыры урамында, балалар бакчасы өчен – Вишневский урамы, 61а адресы буенча урнашкан торак йорт тирәсендә).

Яңгыр һәм кар суларын чыгару өчен (исәпләнгән күләме – секундына 6986,69 л) проект белән түбәндәгеләр каралган:

- планлаштырыла торган балалар бакчасы тирәсендә яңгыр сулары канализациясенең гамәлдәге челтәрләрен үзгәртеп салу һәм демонтажлау;

- Нестеров Чокыры урамында яңгыр суларын кабул итү җайланмалары белән яңа челтәрләр төзү (Заслонов урамы тирәсендәге челтәрләрдән Вишневский урамындагы тоташтыру ноктасына кадәр);

- планлаштырыла торган күпфатирлы торак төзелеше территориясендә яңгыр суларын кабул итү җайланмалары белән челтәрләр төзү һәм Нестеров Чокыры урамында планлаштырыла торган челтәрләргә тоташтырылачак локаль чистарту корылмалары төзү.

Планлаштырыла торган төзелеш өчен җылылык белән тәэмин итүнең таләп ителгән егәрлеге – сәгатенә 3,522 Гкал, планлаштырыла торган балалар бакчасы (80 урынга исәпләнгән) өчен сәгатенә 0,283 Гкал тәшкил итә. Планлаштырыла торган төзелешне җылылык белән тәэмин итү өчен, Заслонов урамы, 26 адресы буенча урнашкан котельный бинасы янында җылылык челтәрләренә тоташтырып, җылылык челтәрләре урнаштыру каралган. Күрсәтелгән җылылык чыганагының җитәрлек булмавын истә тотып, гамәлдәге ике КСВ-2,9 казанын ярдәмче җылылык-механик җиһаз һәм автоматлаштырылган горелка булган ике КВ-ГМ 6,0 казанына алмаштыру зарур. Әлеге эшләрне башкарганда, егәрлеге планлаштырыла торган балалар бакчасына бәйле рәвештә арту сәбәпле, котельныйның санитар-сак зонасын кыскарту буенча чараларны исәпкә алырга кирәк.

Планлаштырыла торган торак төзелешенең исәпләнгән электр куәте –

1244,09 кВт, балалар бакчасы өчен 130 кВт тәшкил итә. Электр белән тәэмин итүне гамәлдәге БКТП-2377 блоклы комплектлы трансформатор подстанциясеннән һәм яңа блоклы комплектлы трансформатор подстанциясеннән гамәлгә ашыру каралган, соңгысы үз чиратында БКТП-2377 блоклы комплектлы трансформатор подстанциясенә тоташа»;

1.6. түбәндәге эчтәлекле 7 пункт белән тулыландырырга:

«7. Нестеров Чокыры урамы тирәсендәге территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмә.

| **Объектның төре** | **Объект** | **Архитектура-төзелеш ягыннан проектлаштыру (экспертиза узуны да кертеп), этап/максималь сроклар (ел)** | **Төзү яки реконструкцияләү, этап/максималь сроклар (ел)** | **Сүтү, этап/максималь сроклар (ел)** |
|---|---|---|---|---|
| Социаль инфраструктура | 80 урынга исәпләнгән балалар бакчасы | I/2 | II/3* | I/2 ** |
| Торак билгеләнешендәге капиталь төзелеш | 690 кв. м мәйданда эченә кертеп-кушып төзелгән торак булмаган билгеләнештәге биналар белән гомуми мәйданы 29000 кв.м булган күпфатирлы торак төзелеше | I/2 | II/3 | |
| Транспорт инфраструктурасы | Заслонов урамындагы һәм Нестеров Чокыры урамындагы юл | I/1 | II/2 | |
| Инженерлык инфраструктурасы | Локаль чистарту корылмасы, трансформатор подстанциясе, инженерлык челтәрләре | I/2 | II/3 | |

*Срогы дәүләт һәм муниципаль программаларны формалаштырганда ачыкланырга мөмкин.
**Яңа төзелеш зонасына эләгә торган инженерлык челтәрләрен күчерү, демонтажлау, капиталь төзелеш объектларын сүтү.

2. Кызыл линияләр, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны, җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән

планлаштыру проекты сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләргә 1 номерлы кушымта нигезендә редакцияләргә.

3. Кызыл линияләр, юлларны, урамнарны, элемтә линияләрен, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларын билгели торган линияләр күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләргә 2 номерлы кушымта нигезендә редакцияләргә.


4. Борылыш нокталары координаталары белән кызыл линияләр күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымы фрагментын, әлеге үзгәрешләргә 4 номерлы кушымта нигезендә билгеләнә торган кызыл линияләрнең борылыш нокталары координаталары исемлеге белән тулыландырып, әлеге үзгәрешләргә 3 номерлы кушымта нигезендә редакцияләргә.

Борылыш нокталары координаталары белән кызыл линияләр күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымы фрагменты хезмәт урынында файдалана торган документ булып санала һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырылырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

______________________

Фрагмент чертежа проекта планировки с указанием красных линий, границ зон планируемого размещения объектов социально-культурного и коммунально-бытового назначения, иных объектов капитального строительств местного значения

Приложение №1 к изменениям, вносимым в проект планировки территории "Аметьево", утвержденный постановлением Исполнительного комитета г.Казани от 31.12.2015 №4666




| № | Наименование | Параметр | Примечание |
|---|---|---|---|
| 1 | Многоквартирная жилая застройка переменной этажности до 25 эт. | 29000 кв.м.жилой площади, 690 кв.м встроенно-пристроенных помещений нежилого назначения | планируемый |
| Д-1 | МБДОУ "Детский сад №15" на 120 мест | | существующий |
| Д-2 | Детский сад на 80 мест | площадь ЗУ 0,31 Га | планируемый |
| БКТП | Блочная комплексная трансформаторная подстанция (ориентировочное место размещение) | - | планируемая |
| ЛОС | Локальные очистные сооружения (ориентировочное место размещение) | - | планируемые |

Условные обозначения

- Граница внесения изменений
- Красные линии утвержденные
- Отменяемые красные линии
- Красные линии устанавливаемые
- Дороги и проезды

Зоны размещения объектов капитального строительства (существующие объекты)

- Зона размещения многоэтажной жилой застройки
- Зона размещения среднеэтажной жилой застройки
- Зона размещения малоэтажной жилой застройки
- Зона размещения многоэтажной жилой застройки со встроенными объектами обслуживания
- Зона размещения объектов инженерной инфраструктуры
- Зона размещения смешенной жилой застройки
- Зона размещения объектов автомобильного транспорта
- Зона размещения объектов дошкольного образования

Зоны планируемого размещения объектов капитального строительства

Территории жилой застройки

- Зона планируемого размещения многоэтажной жилой застройки

Территории объектов образования и воспитания

- Зона планируемого размещения объектов дошкольного образования

Территории зеленых насаждений


- Зона планируемого размещения озелененных территорий общего пользования

Общественно-деловые территории

- Зона планируемого размещения общественно-деловой зоны

Фрагмент чертежа проекта планировки с указанием красных линий, линий, обозначающих дороги, улицы, проезды, линии связи, объекты инженерной и транспортной инфраструктур

Приложение №2 к изменениям, вносимым в проект планировки территории "Аметьево", утвержденный постановлением Исполнительного комитета г.Казани от 31.12.2015 №4666




| № | Наименование | Примечание |
| --- | --- | --- |
| БКТП | Блочная комплексная трансформаторная подстанция (ориентировочное место размещение) | планируемая |
| ЛОС | Локальные очистные сооружения (ориентировочное место размещение) | планируемые |